УДК 371.2

# ТӨРКЕСТАНДА ҖӘДИТ МӘКТӘПЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАРЛАР (XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ҺӘМ ҮЗБӘК ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА)

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның Төркестанда җәдит мәктәпләрен оештыру, татар һәм җирле халык балаларына белем бирүдәге эшчәнлеге яктыртыла. XX гасыр башы, совет чоры һәм хәзерге галимнәрнең әлеге проблемага карата фикерләре тикшерелә. XX гасыр башы татар һәм үзбәк вакытлы матбугаты материалларына таянып, аерым мәктәп һәм мәдрәсәләрнең ачылу тарихы яктыртыла. Җирле милләт вәкилләренең татар мөгаллимнәренең эшчәнлегенә карата карашлары тасвирлана. Татар авторларының Төркестандагы җәдит мәктәпләрендә файдаланылган дәреслекләре һәм аларның җирле халыклар телләрендә дәреслекләр язылуга ясаган йогынтысы ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** җәдитчелек, Урта Азия, Төркестан, татар мөгаллимнәре, ысулы саутия, җәдит мәктәпләре һәм мәдрәсәләре, кардәш халыклар, мәгариф

**Сылтама ясау өчен**: Муртазина Л.Р. Төркестанда җәдит мәктәпләре һәм татарлар (XX гасыр башы татар һәм үзбәк вакытлы матбугаты материаллары буенча) // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 3. С. 466–480. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-3.466-480

XIX гасырның соңгы чирегендә барлыкка килгән, Идел-Урал буе, Кырым, Кавказ һәм Урта Азия мөселманнарын үз эченә бөтереп алган җәдитчелек хәрәкәтенең киң җәелүендә, билгеле булганча, татарларның роле зур. Җәдитчелеккә мөселман мәгариф системасын үзгәртеп кору, мәгърифәтчелек-агарту фикерләренең яңа баскычка күтәрелүе күзлегеннән чыгып караганда бу үзенчәлек аеруча ачык күренә.

Төркестанда, казакъ-кыргыз далаларында мәгърифәт тарату, җирле халыкларга белем бирү, җәдиди мәктәпләр ачуда татарларның башлап йөрүе мәгълүм. Совет чорында бу үзенчәлеккә зур игътибар бирелмәде,

татарларның Төркестанда, Урта Азиядәге эшчәнлекләренә нигездә иҗтимагый-сәяси, революцион фактор буларак, коммунистик идеология күзлегеннән чыгып каралды. Һәрхәлдә, совет чорында язылган фәнни хезмәтләрдә казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән һ.б. төрки халыкларның белем һәм тәрбия системалары тарихында татарлар калдырган эз ассызыкланмады. Хәлбуки, революциягә кадәрге һәм совет чорының беренче елларында язылган, Урта Азия халыкларының мәгарифен, мәдәниятен, этнологиясен өйрәнгән кайбер тикшерүчеләрнең хезмәтләрендә, аерым алганда, А.И. Добромыслов, Н.А. Бобровников, В.В. Бартольд һ.б. язмаларында татарларның Төркестан халыкларының мәдәнияте һәм мәгарифе үсешендә шактый зур эш башкарганлыклары күрсәтелә (Бартольд 1927; Бобровников 1913; Добромыслов 1912). А.И. Добромыслов, мәсәлән, “Россия мөселманнары арасында мәгърифәт таратуда җитәкчелек ролен, иң белемле һәм алга киткән халык буларак, татарлар үз кулларына алды”, – дип язды (Добромыслов 1912: 252). Соңгы елларда барлыкка килгән хезмәтләрдә, кыргыз, үзбәк, казах һ.б. авторлар тарафыннан язылган китап һәм мәкаләләрдә әлеге проблеманы беркадәр яктыртуга, тарихи дөреслекне кайтаруга омтылыш күзәтелә (Галимова 2015; Иманкулов 2016; Карлыбаев 2012; Кубатова 2012; Мамытов 1992; Насретдинова 2011; Расулов 2005).

Татарлар һәм Урта Азия халыкларының мәгариф өлкәсендәге бәйләнешләре турында сүз алып барганда, әлбәттә, беренче чиратта дини белем бирүдә дөньякүләм әһәмияткә ия булган Сәмәрканд, Бохара мәдрәсәләре һәм аларда белем эстәгән татар шәкертләре, шулар арасында иң мәшһүрләре – Габденнасыйр Курсави, Баһаветдин ибн Собхан, Шиһабетдин Мәрҗани, Әбелмәних Каргалый, Габдрәхим Утыз-Имәни, Галимҗан Барудиларны искә алу мөһим. Урта Азиянең атаклы гыйлем ияләре белән очрашу, алардан белем алу, күп гасырлык тарихка ия булган мәдәният белән танышу аларның дини, фәлсәфи, фәнни карашлары формалашуга йогынты ясаган, әлеге фикерләрнең Идел-Урал буенда таралуына булышлык иткән. Шул ук вакытта хәзергәчә әлеге уку йортларында укыган башка татар шәкертләре турында мәгълүмат аз булуны, тормыш һәм эшчәнлекләре өйрәнелмәүне дә искә алырга кирәк. Кайбер чыганаклар, әйтик, Т. Әйди мәгълүматларына караганда, бары тик 1893 елда гына Бохара шәһәрендә йөзләп татар егете укыган (Әйди 2015: 415).

Әлбәттә, татарларның башка төрки халыклар белән ныклы бәйләнешләр булдыруында шактый зур тарихлы икътисади-сәүдә мөнәсәбәтләре дә, дин һәм гореф-гадәтләр уртаклыгы, тел якынлыгы да зур әһәмияткә ия. Патша хакимиятенең татарларны үз сәясәтендә, тәрҗемәчелек, дипломатия хезмәтендә файдалануы билгеле. Ләкин шул ук вакытта татарлар, кайда гына яшәсәләр дә, “үзләренең милләтләрен югалтмыйлар, саклап киләләр, форсат чыккан саен башка дин кардәшләрен тәрәккый итүдә тырышалар” (Измайлов 1927), далада ислам динен ныгытуда, төрки-татар телен урнаштыруда, мәгърифәт таратуда зур эш

башкаралар. Җәдитчелек агымы җәелү, яңача, аваз ысулына (“ысулы җәдит”, “ысулы саутия”) нигезләнгән, дөньяви белемнәр таратуга юнәлдерелгән мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килә башлау белән татарларның Төркестандагы роле тагын да арткан.

Мөгаллимлек иткән күп кенә татарларның (алар арасында Мифтахетдин Акмулла, Муса Акъегет, Шәехзадә Бабич, Габдрәшит Ибраһимов, Галимҗан Ибраһимов, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири, Кыям Юлдашев кебек бик күп язучылар, галимнәр бар) башлангыч чор эшчәнлеге Төркестандагы мәгърифәтчелек хезмәте белән бәйле. Аерым муллалар, мөгаллимнәрнең, “Галия”, “Мөхәммәдия”, “Хөсәения” кебек алдынгы мәдрәсәләрдә белем алучы күп кенә татар шәкертләренең җәйге айларда кыргыз-казакъ далаларына чыгып балалар укытуы билгеле. Кардәш халыкларга белем бирү белән беррәттән, шәкертләр беркадәр матди якларын да кайгыртканнар, җылы, коры һава шартларында сәламәтлекләрен ныгытканнар (Казакъ эчендәге шәкертләр 1910). Тик шулай да төп максат һәм изге бурыч буларак мәдәни-агарту эше каралган. Җәдитчелек хәрәкәте тарала башлау белән, татар мөгаллимнәренең эшчәнлеге тагын да киңәйгән.

Кыргыз тикшеренүчеләре билгеләп үткәнчә, Урта Азиядә җәдитчелек таралуны татар мәгърифәтчеләре эшчәнлегеннән аерып карау һич мөмкин түгел (Кубатова 2012: 26). Кайбер галимнәрнең, әйтик, Б.Б. Зулуевның, җәдитчелекнең барлыкка килүен турыдан-туры Урта Азия белән бәйләп каравына карамастан (Зулуев 2018), әлеге хәрәкәтнең иң беренче чиратта Идел-Урал буйларында, Кырымда формалашуын, нәкъ менә татар-башкорт мөгаллимнәренең тырышлыгы аркасында башка төбәкләргә, шул исәптән Төркестанга да таралуын, күп галимнәр таный (Кубатова 2012: 54).

Билгеле булганча, җәдитчелекнең нигезләре Г. Курсави, Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә салынса да, мәгариф өлкәсендә аны практик яктан тормышка ашырган, җәдиди мәктәпләргә нигез салган, белем бирүдә яңа аваз ысулын беренчеләрдән булып файдалануга кертүче, шуңа нигезләнеп дәреслекләр төзүче педагог Исмәгыйль Гаспринский була. Ул Россиянең төрле төбәкләрендә йөреп, яңа мәктәпләр булдыру эшенә күзәтчелек иткән, фикри ярдәм күрсәткән. 1893 һәм 1908 елларда Гаспринский Төркестанда да була (Турсунова 2017: 24), соңыннан бу өлкәләрдә яшәүче халыкларның тарихына, мәдәниятенә, мәгарифенә багышланган хезмәтен яза (Гаспринский 1900). Россиянең күп шәһәрләрендә Гаспринский исемендәге мәктәпләр ачылу да[1] әлеге шәхеснең мөселман халыкларының мәгарифе тарихында тоткан урынын ассызыклый. Ләкин шул ук вакытта, Идел–Урал буе татарларының, нугайларның (Төркестанда Идел буе татарларын “нугай” атамасы белән йөртү киң таралган була; ә җәдит мәктәпләре, бигрәк тә “Фирганә өлкәсендә, “нугай мәктәпләре” “исеме илә

[1] И.Гаспринский исемендәге мәктәп Каракол шәһәрендә, Ташкентта, 1918 елда Казанда һәм башка шәһәрләрдә ачыла.

шөһрәт тапмыштыр. Чөнки бу мәктәпләрнең Фирганәдә иң әүвәл ачмыш затлар татар кардәшләремез булып, халыкны мәдәнияткә башламак ният мөкатдәсе илә ачкан булалар" (Төркестан мәктәпләре 1914) әлеге милли идеяне таратуга һәм үстерүгә, аны практик яктан тормышка ашыруга керткән өлешләрен аерым игътибарга алу мөһим. Иң беренче чиратта, татарлар (аеруча Төркестан җирләрендә төпләнеп яшәгәннәре) оештырган мәктәпнең беренче чиратта татар балалары өчен ачылуын истә тотарга кирәк. Бу мәктәпләрнең уңышын күреп, җирле халык та үз балаларын аларга бирергә тырышкан. Әлеге мәктәпләр үрнәгендә башка милли мәктәпләр барлыкка килгән.

1910 елда "Вакыт" газетасында дөнья күргән "Бохарада ысулы җәдидә мажарасының холясасе" дигән мәкаләдә бәян ителгәнчә, Бохарада 1907–1908 елларда ачылган җәдит мәктәбендә татар балаларын укытыр өчен Буадан бер мөгаллим чакыртыла. Тәртип белән эшләгән, укуда (имтиханнар буенча) югары нәтиҗәләр күрсәткән бу мәктәптән күреп бохаралылар да үз балаларына шул мәктәп үрнәгендә бер мәктәп ачалар. Иске мәктәптә 15 ел укып та, белем дәрәҗәсе бик түбән булган 25 яшьлек егетләр, 4–5 ай укып, имтиханда югары нәтиҗәләр күрсәтәләр. Халык, шул рәвешле, җәдит мәктәпләренең файдалы булуын күрә, балаларын укырга бирүче аталар саны арта (Гайн Шин 1910).

Ләкин җәмәгатьчелек арасында бу мәктәпләргә карата караш бик каршылыклы булган. Алда искә алынган Бохара мәктәбендә уздырылган имтихан вакытында алдынгы карашлы дин әһелләре әлеге мәктәпне яклап нотык тотса, иске мәктәпләрдә белем бирүне дәвам итүче, традицион системаны гына таныган кадимче муллалар әлеге мәктәпкә каршы чыгалар. Алар фикеренчә, җәдит мәктәпләрендәге өч нәрсә дөрес түгел: партага утыртып укыту; ысулы җәдидә белән укытучыларның "тәмәкече булулары имеш" һәм "әҗнәби милләтнең (нугайларның) ысулы тәгълимне күрсәтүе ярамый имеш"; "ысулы җәдидә кертеп, Бохараны харап итәләр, дәһри булалар, намаз вә уразаны шәйгә алмыйлар" һ.б. Шуларны сәбәп итеп, мәктәпне ябырга карар итәләр (Гайн Шин 1910).

Татар мәктәпләре һәм мөгаллимнәре белән бәйләп каралган тагын бер күренешне искә алып үтми мөмкин түгел. Шул заманның үзбәк газеталары хәбәр иткәнчә, бу нугай мәктәпләренең тиз артуы, бер яктан караганда, күңелле күренеш булса да, "укый-яза белә торган һәрбер кешенең күңелендә бер "нугай мәктәбе" ачмак, бай булмак фикере төшү" (Төркестан мәктәпләре 1914) күзәтелү аларның эчтәлегенең ярлылануы, акча эшләү чарасына гына әверелеп калу куркынычы булу хакында сөйли. Ләкин мондый ислах кылынмаган, үзгәрергә теләмәгән, педагогик нигезләргә корылмаган мәктәпләр озак яши алмаган, бары тик көчлеләре генә үсеш алган.

Күпчелек татар мөгаллимнәре педагоглык эшен вакытлыча, килеп-китеп кенә түгел, ә Төркестанда яшәп, шунда төпләнеп алып барганнар. Араларында шул төбәктә туып-үскәннәре дә булган. Ләкин шул нәрсә күзгә чалына: алар барысы диярлек Идел буе-Урал мәдрәсәләрен тәмамлап

чыкканнар. “Икъбалия” мәдрәсәсенең мөдәррисләре З. Ваһапов, М.Смаков, мәсәлән, Троицкидагы “Рәсулия” һәм Уфадагы “Галия” мәдрәсәләрендә белем алганнар, Нургали Мамин исә “Мөхәммәдия”дә укыган һ.б. (Кубатова 2012: 53).

Галимнәр билгеләвенчә, Төркестанда җәдиди мәктәпләр XIX гасырның соңгы елларында барлыкка килә башлый (Бартольд 1927: 136). Сәмәрканд шәһәрендә аваз ысулы белән укыта торган тәҗрибә мәктәбе 1893 елда ук Гани Хөсәеновның матди ярдәме белән оеша (Сәмәрканд мәктәбе 1893). Кайбер башка мәгълүматлар буенча, бу мәктәп Габдуллин атлы сәүдәгәр тырышлыгы белән ачыла, мәктәпнең эшен җайга салу өчен И. Гаспринский да чакыртып алына (Очерки истории школы 1976: 489). XX гасыр башы вакытлы матбугаты мәгълүматларына караганда, бу өлкәләрдә җәдит мәктәпләре якынча 1902–1903 еллардан бирле эшләп килә (Расулов 2005). 1905–1907 еллардан соң мәктәпләрнең саны күзгә күренеп арта.

Яңа ысуллы мәктәпләр барлыкка килү ике төрле юл белән барган: иске, кадими мәктәпләргә ислах ясау һәм яңа нигезләргә корылган җәдит мәктәпләре оештыру. Фәндә “җәдит мәктәпләре” буларак билгеле булган бу мәктәпләрне XX гасыр башы матбугатында (аерым алганда, үзбәк телендә дөнья күргән газеталарда) ике төргә бүлеп карау күренеше дә күзәтелә. “Садаи Төркестан” газетасы, мәсәлән, “ысулы саутия” мәктәпләрен, “җәдит” мәктәпләреннән аермалы буларак, иске кадим мәктәпләреннән үзгәртеп ясалган мәктәпләр, һәм иске мәктәпләр белән чагыштырганда, “бераз тәртипкә кергән” мәктәпләр дип саный: аларда сыйныфларга бүленеш, парталар куллану, аваз ысулы белән укыту кертелгән, ләкин программалар юк, “фөнүн җәдидә”ләр укытылмый (Төркестан мәктәпләре 1914). Күп очракта педагогик белеме булмаган, “ысулы саутиянең ни икәнендән хәбәрсез затлар бу мәктәпләрне иске ысулдан һәм хәрабәлек бер хәлгә китерделәр. Хәзердә (мәкалә 1914 елда дөнья күргән – Л.М.) Ташкент, Хоканд кеби олуг шәһәрләрдә вә бәгъзе кышлакларда бондай буяма мәктәпләрдән берничә danә тапмак мөмкиндер”, – дип яза газета. Бу күренеш, автор билгеләвенчә, “моннан биш элек заманнарда иде”, ягъни 1908 елларга кадәр. Аннан соңгы чор, газета билгеләвенчә, җәдит мәктәпләре эшчәнлеге белән бәйле. “Ысулы җәдидә мәктәпләре “новометодный” гыйнваны илә хөкүмәт тарафыннан рәсмән танылмыш мөрәттиб вә мөнтазәм мәктәпләрдер”. Аларда программалар, дәреслекләр кулланыла, педагогик белемгә ия булган мөгаллимнәр укыта. Җәдит мәктәпләрендә “һәр ел май аенда имтихан үткәрелә”, җирле халык телендә язылган дәреслекләр файдаланыла (Дәүли 1914). Бу классификациянең нигезендә җәдит мәктәпләре эшчәнлегенең чорларына бәйлелек принцибы ята. Чыннан да, беренче дәвердә мәктәпләр оешу хаотик рәвештә бара, махсус программалар булмый һ.б., ләкин бу гына әлеге ике чорга караган мәктәпләрне ике аерым төргә аерып карарга һәм аларда эшләгән татар мөгаллимнәренең ролен киметергә мөмкинлек

бирми. Моннан тыш, мәкаләнең 1910 елдан соң, хөкүмәт тарафыннан Төркестандагы татар мөгаллимнәренә карата караш беркадәр үзгәргән чорда[2] язылуын да истә тотарга кирәк. Шул сәбәпле җәдит мәктәпләре дигәндә җирле халык вәкилләре мөгаллимлек иткән, җирле авторлар тарафыннан төзелгән дәреслекләр белән укытылган мәктәпләрне генә атау, аларга һәрьяклап уңай карау сизелә. Моннан тыш, мөгаен, хөкүмәт сәясәтенә бәйле рәвештә, бу чорда Төркестан җәмәгатьчелеге арасында да татар мөгаллимнәренә булган мөнәсәбәт беркадәр үзгәрә. "Вакыт" газетасы бу хәлгә үзенең фикерен белдереп: "Гүя казакъларның бәгъзе голямасы татар хәлфәләренең казакъ балаларын укытуларына эче поша вә шул хәлфәләргә каршы хәрәкәт итәләр имеш. Әгәр дөрес булса, бу бик күңелсез бер эштер. Милләтнең хәл вә истикъбален кайгыртырга тиеш булган голяма вә олуглар, аз булса да халыкка хезмәт итүчеләрне үзләренең химаяләренә алырга, анларга яхшы күз берлән карап, ярдәмдә булышырга тиеш иде. Заманыбыз казакълык, татарлык яки картлык-яшьлек фәрәкъләре илә маташа торган заман түгел, мәдәният вә тәрәккъый юлына керер өчен тырыша торган замандыр," – дип язып чыга (Казакъ эчендәге шәкертләр 1910). Төркестандагы җәдит мәктәпләре эшчәнлегендә татар мөгаллимнәренең ролен күреп бетермәскә тырышу кайбер хәзерге авторларның хезмәтләрендә дә чагылыш таба (Казакъ эчендәге шәкертләр 1910; Турсунова 2017).

Татар вакытлы матбугатында Төркестанда җәдит мәктәпләрен оештыруда башлап йөргән, күп көч куйган аерым татар мөгаллимнәре турында мәгълүматлар очрый. "Шура" журналының 1913 елгы 23 нче санында, мәсәлән, "Хоканд мөселманнарының балаларына "ысулы саутия" илә башлап укытучы" мөгаллим Сәлахетдин Сираҗетдин улының эшчәнлеге шактый тәфсилле тасвирлана (Хәйрулла Әһлиулла 1913). Әлеге мәкалә гомумән Төркестанда җәдит мәктәпләрендә хезмәт куйган татар мөгаллимнәренең эшчәнлеген күзалларга мөмкинлек бирү ягыннан үзенчәлекле. Ул шулай ук татар һәм гомумән төрки-мөселман педагогик фикере тарихында эз калдырган, моңарчы билгесез яки аз билгеле булган педагогларны ачыклау күзлегеннән караганда да кыйммәтле.

Сәлахетдин әфәнденең атасы Сираҗетдин чыгышы белән Сембер губернасы Иске Тинчәли авылыннан була, яшь вакытында Әҗе авылына (Рязань өлкәсендәге авыл – Л.М.) күченеп килеп, анда мөгаллимлек итә. Сәлахетдин 11 яшенәчә атасыннан белем алганнан соң, Касыйм өязе

[2] 1910 елда Эчке эшләр министрлыгының "Татар-мөселман йогынтысына каршы тору өчен чаралар булдыру буенча махсус киңәшмәсе"ннән соң, Төркестанда исламчылык һәм төрекчелек идеяләрен тарату куркынычы тудырган, "дала миссионерлары" буларак кабул ителгән татар мөгаллимнәренә укытучылык итү эше тыела. 1912 елда Төркестанда "сарт балаларын сарт мөгаллиме генә укытырга тиешлек" турындагы карар чыкканнан соң, татарлар белем бирүдән читләштерелә.

Яубаш авылы мәдрәсәсенә барып, 20 яшенә кадәр шунда белем ала. Якындагы Татарбай авылында яңа ысуллы мәктәп ачылганнан соң, кичләрен шунда барып укый. Шулай итеп, ул бер үк вакытта “иске фәннән” дә, “яңа фәннән ” дә мәгълүмат ала. Мөгаллимлеккә шәһадәтнамә алганнан соң, Сәлахетдин Фирганә якларына юл тота (“мөгаллим булу нияте илә түгел, үзен эзләгәнгә”). Коканд шәһәренә килгәннән соң, Әхмәт бай Хөсәеновның шәһәрдәге кибетенә эшкә урнаша, бер үк вакытта Әхмәт байның доверенные Галиәсгар Сутюшевның улын укытырга алына. Бер ай эчендә баланың бик күп нәрсәләргә өйрәнүен күргән Галиәсгар әфәнде берничә дусты белән бергәләп Сәлахетдингә мәктәп ачып бирергә карар кылалар, бу турыда Әхмәт байга да мөрәҗәгать итәләр. Әхмәт бай: “Минем хезмәтемдә ала торган жалуниясен биреп торырмын,” – дип, яшь мөгаллимгә матди ярдәм күрсәтәчәген белдерә. Шулай итеп, 1900 елның 11 февралендә Коканд шәһәрендә татарлар тарафыннан булдырылган бинада ысулы саутия мәктәбе эшли башлый.

Кокандта моңа кадәр Шакир Сөләйманиның[3] иске ысуллы мәктәбе эшләп килгәнгәме, әллә “җиңел укыту” сүзенең мәгънәсенә төшенеп бетә алмау сәбәплеме, халык яңа мәктәпкә балаларын бирергә бик ашыгып тормый – анда барлыгы 6 бала гына укый башлый. Озакламый, аларның уңышларын күреп, күпләр әлеге мәктәпкә тартыла башлый – 6 айдан соң үткәрелгән имтиханда балалар саны 20 гә тула. Имтихан мәҗлесенә җыелган татарлар, сартлар (Төркестандагы төрки һәм фарсытелле утрак шәһәр халкы – Л.М.) балаларның тиз арада укуда ирешкән уңышларын күреп, хәйран калалар. “Чөнки бу тарафларда “уку-укыту” дигән сүз булса да, 9–10 яшеннән мәктәпкә кереп, ниһаять 16–17 га җиткәндә хәреф тану, 20 ләргә җиткәндә үз исемен яза алудан гыйбарәт иде. Инде 8–9 яшьләрдәге балалар зурлар белмәгәнне белүләре, муллалар һәм мәхдүмнәргә әса ула торган кечек кенә балаларның язу яза белүләре Шәрыкның садә халкын йомшартты”, – дип яза мәкалә авторы Әһлиулла Хәйрулла углы (Хәйрулла Әһлиулла 1913: 718). Бу Коканд шәһәрендә ысул саутия мәктәбенең беренче имтиханы була. Яңа ысул нигезендә сарт балаларын укытып, аларга язу таныту турындагы хәбәр бөтен өязгә тарала. Озакламый, балалар саны күбәю сәбәпле, мәктәп яңа, зуррак бинага күчерелә – Гомәр хаҗи дигән бер бай үз мәхәлләсендә мәктәпханә салдыра һәм Сәлахетдин мөгаллимне шунда күчерә. Мәктәптә көндез 100 бала, кичен зуррак яшьләр укый башлый. Сәлахетдин мәктәбе – Кокандта ысулы җәдит мәктәбенең беренчесе, озакламый берничә татар мөгаллиме килеп, Сәлахетдин әфәндедән өйрәнеп чыгып, үзләре мәктәп ачалар.

---

[3] Сөләймани Шакир бине Мөхәммәтзакир, төрки халыклар арасында бик популяр булган “Тарихе Ислам” (Беренче табгысы. Казан: Бр.Кәримовлар, 1910. 224 б.) китабының авторы. Дүрт томлык әлеге китап кириллицага күчерелеп, 2019 елда “Хозур” нәшриятында кабат басылып чыкты.

Ләкин, уңай якларны санау белән беррәттән, автор әлеге күренешнең кимчелекле якларына да тукталып китә. "Ысул җәдидә белән укыту җиңел икән, дип коры язу танучы берничә адәм дә бала җыеп акча суга башладылар. Боларны күреп, җәдитчә дә түгел, кадимчә дә түгел, дип укытучы дамеллалар да кара такта алып балалар яздырып-боздырып укыта башладылар. Берничә язу танучы татар разносчиклары, дворниклары да Сәлах әфәндедән, бәгъзеләре Шакир әфәндегә айга 10–15 сум биреп ысул җәдидә тәртибен үгрәнделәр һәм мәктәп ачып балалар укыта башладылар", – ди (Хәйрулла Әһлиулла 1913: 718). Бу, әлбәттә, әлеге мәктәпләрнең данын беркадәр киметкән һәм татарлар башлап җибәргән эшкә һәм татар мөгаллимнәренә карата тискәре караш формалаштыруга сәбәп булган. Әмма шулай да, Ә.Хәйрулла билгеләп үткәнчә, "Һәрничек булса да, Хокандта "ысул җәдит" исемендә мәктәп күбәйде, хәтта 20 җирдә мәктәпханә ачылды" (Хәйрулла Әһлиулла 1913: 718). Бу мәктәпләрдә аз дигәндә 70, иң күбе 300 тирәсе бала укыганын (Хәйрулла Әһлиулла 1913: 718) исәпкә алсак, моңа кадәр укудан мәхрүм булган никадәр җирле халык балаларының мәктәпкә якынаюын, һәм, димәк, күпмедер дәрәҗәдә белем алуын күз алдына китерергә мөмкин.

Төркестанда җәдит мәктәпләренә нигез салган татарлар арасында үзбәк балаларын укыткан Ш. Мохтар, З. Габделвәлиев, Ташкентта И. Гаспринский исемендәге мәктәпне ачуда катнашкан Әбүбәкер Диваев, Габдулла Биги, Булат Сәлиев, Габдрахман Чанышев, Һади һәм Хәбибрахман Фәйзиләрне атарга мөмкин (Әйди 2015: 400). Курбатова тикшеренүләре буенча, 1913 елда татар укытучыларының саны 40лап була. Тарихта каракалпаклар өчен җәдит мәктәбе оештыру өчен 1915 елда Төркестаннан биш татар чакырылуы, алар арасында Иманкулов атлы кеше дә булуы билгеле (Карлыбаев 2012: 114).

Оренбург өлкәсе дәүләт архивында саклanган бер документка караганда, XX гасыр башында Төркестан халкына мәгърифәт таратуда катнашкан мөгаллимнәр арасында алда искә алынган "Мөхәммәдия", "Галия", "Хөсәения" мәдрәсәләреннән тыш, "Касыймия", Буа, Чистай, Сембер һәм Кышкар мәдрәсәләрен тәмамлаучылар да күп була. 1912–1913 уку елында Казан шәһәреннән килүчеләр арасында Уфа губернасында туыпүскән, "Касыймия"дә белем алган, Җидесу вилаятенең Сергиополь шәһәрендә балалар укыткан Мәүлет Латыйпов, чыгышы белән Хвалын өлкәсеннән булган, шул ук мәдрәсәне тәмамлаган Хәсән Үзбәков, Новоузенск өязеннән чыккан, Казан шәһәрендә яшәүче Гатаулла Әхмәров, казан татарларыннан Харис һәм Һади Давытовлар һ.б. атала (ГАОО: Б. 21 и.я., 206).

Моннан тыш, соңгы чор тикшеренүләрендә Төркестанда мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып барган Надыршин Салих Ми(д)хәт улы (1879 елда Казан губернасы Чистай өязе Яңа Әмзә авылында туган) турындагы мәгълүматлар искә алына. Ул 1898 елда Казанда мәдрәсә тәмамлаганнан соң, Тамбов, Саратов губерналарында мөгаллимлек иткән, 1905 елда Каракол шәһәренә килгән, андагы татар җәдит мәктәбенә укытучы булып

урнашкан, совет чорында И. Гаспринский исемендәге мәктәпнең директоры булып эшләгән (Кубатова 2012: 46). Икенче бер татар мөгаллиме Сабир Гыйльманов (1879–1917) 1902 елдан шул ук Каракол шәһәрендәге татар җәдит мәктәбендә, соңрак Токмак шәһәрендәге "Икбалия" мәдрәсәсендә укыткан, кыргыз тематикасына багышланган әсәрләр һәм мәкаләләр белән татар матбугатында чыгыш ясаган (Мамытов 1992: 15–16). Караколда мөгаллимлек иткән татарлар арасында шулай ук Мөҗазиров Әхмәтсадыйк, Рәхимова Диләфрүз, Айтуганов Ситдыйк, Ашимов Разыйк, Уфа шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаган Хәсәнҗан Баязитов, Уфадан Хуҗагали Рафиков, "Галия"дә укыган Әхмәт Абдулладигин (?), Чистай өязеннән Солтан Черкасов һ.б. исем-фамилияләре дә бар. 1915 елда Уфа шәһәреннән килгән Хәби Якубов һәм Хәби Рәхимовлар Пишпек, Токмак шәһәрләрендәге мәдрәсәләрдә укыта башлаганнар (Кубатова 2012: 46, 52–54).

Гомумән алганда, җәдит мәктәпләренең һәм аларда хезмәт куйган мөгаллимнәрнең педагогик эшчәнлеге җирле халыклар арасында абруй казана. "Садаи Төркестан" газетасы язуынча, "Бу мәктәпләрнең мөгаллимнәренең бәгъзеләре мөгаллим диярлек гайрәтле, истигъдадлы вә кабилиятле. Бу адәмнәр балаларның рухын күтәрмәктә алларындагы җәһаләт вә наданлык зәңене гыйлем вә әдәп нуры илә юып нурландырмак вә зыяландырмак өчен хезмәт кыйлмактадыр" (Дәүли 1914). Дала халкы арасында яңача фикерләр тарала башлауда да әлеге мәктәпләрнең роле зур булуын шул заманның алдынгы карашлы затлары таный. Сасыккүлдә мөгаллимлек иткән Мәгъжан Жомабаев[4] билгеләп үткәнчә, 1910 еллар башына "аз бер заманда татарларны хәйле тәрәкъкый иттергән" "ысулы җәдидә" казакълар арасына да керә башлый, "ысулы җәдит" кирәк дип сөйләнүче шәкертләр, мәдрәсә салу артыннан йөрүчеләр күренгәли (Җомабаев 1910). Татарлар исә, күбәйгәннән-күбәяләр, "наданлык дәрьясына чумган даланы тергезәләр, мәхәллә тәшкил итеп, мәктәп вә мәсҗетләр ачкалыйлар, нәшре мәгарифкә хезмәт итәләр" (Хариҗи хәбәрләр 1910).

Мәдрәсә укытучылары, төп педагоглык хезмәтләреннән тыш, халыкка мәгърифәт таратуның башка юнәлешләрендә дә актив катнашканнар – үзләре белем биргән уку йортларында музыка, театр түгәрәкләре оештырганнар, өй спектакльләре куйганнар. Мәсәлән, Караколда яшәгән 2 нче гильдия сәүдәгәр Х. Габделвәлиевнең өендә оештырылган шундый уен-тамашада аның кызы Нәгыймәнең (язучы Чыңгыз Айтмәтовның әнисе) катнашуы турында мәгълүматлар сакланган (Кубатова 2012: 54).

Татар мөгаллимнәрендә башлангыч белем алган җирле милләт вәкилләре шул ук татарлар үрнәгендә "Мөхәммәдия", "Галия", "Хөсәения", Эстәрлебаш кебек танылган җәдиди мәдрәсәләрдә белем алырга омтылганнар. "Хөсәения"дә, мәсәлән, "Казакъ телен өйрәнү җәмгыяте" дә ачылган була. Кыргыз телендәге "Әлиппе" авторы И. Арабов, беренче

[4] Мәгъжан Жомабаев (1893–1938), казакъ шагыйре, мөгаллим, яңа казакъ әдәбиятына нигез салучы. "Галия" мәдрәсәсендә белем алган.

казакъ галиме Ч. Вәлиханов, казакъ язучысы Б. Майлин һ.б.лар әлеге мәдрәсәләрне тәмамлап чыкканнар. Бары тик 1906–1916 еллар аралыгында гына да «Галия»дә Урта Азиядән килгән 242 шәкерт белем алган (Галимова 2015: 17). Бу хәл, әлбәттә, хөкүмәт даирәләрендә теләктәшлек тапмаган, ул татарларның җирле халыкларга тәэсиреннән, аларның берләшүеннән курыккан: “Читтән килгән мөгаллимнәрнең җирле кыргыз халкына йогынтысы шул дәрәҗәдә зур ки, аларның кайберләре кышкы якта Уфага китәләр, шул ук татарлар тарафыннан шундагы “Галия” мәдрәсәсенә укырга кабул ителәләр, аннан инде үз гаиләләренә чын мәгънәсендә “эшкәртелеп” кайтып керәләр, [...] русларга (бу очракта: хөкүмәткә – Л.М.) карата сансызлык күрсәтәләр” (ГАОО: Б. 21, 22).

Татар мөгаллимнәре, укыту эше белән беррәттән, төрки халыклар арасында татар матбугаты һәм Казан, Оренбург шәһәрләрендә басылып чыккан китаплар таралуга, шулай итеп далага яңача фикерләр үтеп керүгә дә төп сәбәпче булганнар. “Тәрҗеман”, “Вакыт”, “Йолдыз”, “Бәянел-хак”, “Идел”, “Шура” кебек газета-журналлар белән Төркестан яшьләрен татарлар таныштырган (Кубатова 2012: 48). Татарлар үрнәгендә казакъ, үзбәк, кыргыз яшьләре үзләре дә мәкаләләр, китаплар язганнар. Татарлар ярдәмендә һәм аларның җитәкчелегендә үзбәк телендә беренче газеталар барлыкка килгән. Болар: “Тәрәкъкый” (редакторы И. Габитов, 1906), “Хөршид” (1906), “Шөхрәт” (1907, редакторы Әүләнов), “Асия” (Биктимеров, 1908) (Добромыслов 1912: 294).

Җәдит мәктәпләренең дәреслекләр белән тәэмин ителеше мәсьәләсенә килгәндә, аларда укытучы мөгаллимнәрнең беренче чорда татарлар булуын, соңрак татарларда белем алган төркестанлылар белән тулылануын искә алганда, татар авторларының татар телендә махсус татар шәкертләре өчен язылган дәреслекләре кулланылуы табигый. 4–5 ел шул рәвештә дәвам итеп, “аз-аз ислах кылып китаплары химмәтле яшьләремез (җирле халыклар – Л.М.) тарафыннан үз лисанымызда тәртип вә нәшер кылынды вә мәктәп программасына кертелде” (Дәүли 1914). Шул рәвешле, татар авторлары язган дәреслекләр җирле халыкларда үз телләрендә дәреслекләр язуга этәргеч биргән. Җәдит мәктәпләре эшчәнлегенең соңрак чорында үзбәк, казакъ, кыргызлар арасында мөгаллимнәр әзерләнү белән, шул телләрдә дәреслекләр дә барлыкка килә башлый. Ләкин чынлыкта татар дәреслекләре һаман да кулланыла килә. Төркестан район охрана бүлеге документларына караганда, әле 1913 ел башларында да Төркестанда җәдит мәктәпләрендә укыту Казанда басылган татар дәреслекләре нигезендә барган, татар теле укытылган, башка предметлар, әйтик, арифметика, тарих, география шулай ук татар телендә алып барылган, алай гына да түгел, шәригать белемнәрен, Коръәнне, хәтта гарәп телен укытуда да татар теле файдаланылган (ГАОО: Б. 21 и.я.).

Шунысын да искәртү мөһим: җирле халыклар телендәге яңа дәреслекләр күпчелек очракта татар авторларына ияреп язылган. Бу хакта хәтта әлеге дәреслекләрнең исемнәренә карап та фикер йөртергә мөмкин.

Мәсәлән, Саидрасул Саидазизовның үзбәк телендәге “Устози аввал” (“Беренче мөгаллим”) дәреслеге язылуда А.Һ. Максудиның “Мөгаллим әүвәл” әсбабының тәэсире булуы шөбһәсез. А. Авлониның “Биринчи муаллим”, “Иккинчи муаллим” дәреслекләре белән дә шул ук хәл күзәтелсә кирәк.

Җирле халыклар телләрендә дәреслекләр барлыкка килсә дә, татар педагоглары тарафыннан төзелгән әсбаплар озак вакытлар актуальлеген югалтмаган. Шундый китаплар арасында Әхмәтһади Максудиның “Мөгаллим әүвәл”, “Мөгаллим сани” дәреслекләре бар. 1913 елда ул рәсми рәвештә татар һәм рус-татар мәктәпләрендә рөхсәт ителә. Шул елдан алып латин әлифбасы кабул ителгәнчегә кадәр бу дәреслекләр Россиянең мөселманнар яши торган төбәкләрендә кулланылына (Максудий 2018: 4). “Мөгаллим әүвәл”, “Мөгаллим сани” бүгенге көндә дә дини белем бирү системасында, төрки халыкларда гарәп әлифбасын үзләштерүдә иң әһәмиятле дәреслекләр рәтендә йөри. 2018 елда басылып чыккан нөсхә шул хакта сөйли. Соңгы басма үзбәк теленә тәрҗемә ителгән, ә гарәп алфавитын һәм шул нигездә Коръән сурәләрен өйрәнү өчен тәкъдим ителгән материал гарәп телендә бирелгән (Максудий 2018: 5). Әлеге дәреслек татар мөгаллимнәренең Төркестанда, Урта Азиядә яшәүче кардәш халыкларның мәгарифе үсешенә керткән зур өлешен раслаучы саллы мисалларның берсе булып тора.

Шулай итеп, XX гасыр башы татар һәм үзбәк телләрендә дөнья күргән газета һәм журнал материалларына һәм соңгы чор тикшеренүләренә таянып, татар мөгаллимнәренең, татар мәгърифәтчеләренең Төркестанда җәдитчелек хәрәкәтен таратуда һәм җәдит мәктәпләре урнаштыруда, татар һәм башка җирле халыкларның балаларына белем бирүдә, әлеге мәктәпләр өчен методик әсбаплар, дәреслекләр язуда, димәк, төрки халыкларның мәгарифен үстерүдәге рольләре, һичшиксез, зур булган дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Татар халкының гына түгел, гомумән төрки-мөселман педагогик фикере үсешенең иң кызыклы чорларыннан берсе булган җәдитчелек хәрәкәте һәм җәдит мәктәпләренең, аерым педагогларның эшчәнлеге, аларның төрки халыклар мәгарифен, матбугатын, сәнгатен һәм мәдәниятен үстерүдәге роле, һичшиксез, тирәнтен өйрәнелергә тиеш. Бу эштә, тарихи документлар белән беррәттән, XX гасыр башы татар һәм башка төрки телле вакытлы матбугат материаллары кыйммәтле чыганак булып тора.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Әйди 2015 – Әйди Т. Тылсымлы көч // Әйди Т. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Т. 3. Б. 396–427.

Бобровников 1913 – Бобровников Н.А. Русско-туземные училища, мектебы и медресы Средней Азии: путевые заметки. СПб.: Сенат. тип., 1913.

Гайн Шин 1910 – Гайн Шин. Бохарада ысулы җәдидә маҗарасының холясасе // Вакыт. 1910. 18 февраль.

ГАОО – Государственный архив Оренбургской области. Ф. 21. Оп. 2. Д. 618.

Гаспринский 1900 – Гаспринский И. Туркестан улемасы. Бахчисарай: Изд-во типолитогр. газ «Терджиман=Переводчик», 1900.

Дәүли 1914 – Дәүли М. Бездә уку вә укыту // Садаи Төркестан. 1914. 6 май.

Җомабаев 1910 – Мәгъҗан Җомабаев. Казакълар арасында уку һәвәсе // Вакыт. 1910. 30 гыйнвар.

Измайлов 1927 – Измайлов Ш. Төркестан вә татарлар // Олуг Төркестан. 1917. 30 апрель.

Казакъ эчендәге шәкертләр 1910 – Казакъ эчендәге шәкертләр // Вакыт. 1910. 5 июнь.

Очерки истории школы 1976 – Очерки истории школы и педагогической мысли народов СССР. Вторая половина XIX в.. М.: Педагогика, 1976.

Сәмәрканд мәктәбе 1893 – Сәмәрканд мәктәбе (идарәгә мәктүбләрдән) // Тәрҗеман. 1893. 7 ноябрь.

Төркестан мәктәпләре 1914 – Төркестан мәктәпләре // Садаи Төркестан. 1914. 4 апрель.

Харидҗи хәбәрләр 1910 – Харидҗи хәбәрләр // Вакыт. 1910. 26 гыйнвар.

Хәйрулла Әһлиулла 1913 – Хәйрулла Әһлиулла. Төркестан вилаятендә ысуле җәдид тарихы // Шура. 1913. № 23. Б. 717–718.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. Л.: Акад. наук СССР, 1927.

Галимова А.Р. Литературные связи киргизской и татарской поэзии конца XIX – первой половины XX в. Бишкек: Изд-во КРСУ, 2015.

Добромыслов А.И. Ташкент в прошлом и настоящем. Исторический очерк. Ташкент: Электро-паровая типо-литогр. О.А. Порцева, 1912.

Зулуев Б.Б. Литература джадидистов и активность выпускников в общественной жизни // Международный журнал экспериментального образования. 2018. № 6. С. 5–10. http://expeducation.ru/ru/article/view?id=11812

Иманкулов М.К. Развитие системы образования в начале XX в. // Известия Кыргызской академии образования. 2016. № 1 (37). С. 42–46.

Карлыбаев М.А. «Татарские» книги в мектебах Каракалпакии в начале XX в. // Тюркоязычная книга: наследие веков. Казань: ИЯЛИ, 2012. С. 112–114.

Кубатова А.Э. Кыргызстандагы жадидчилик кыймылы (1900–1916). Бишкек: 2012.

Максудий А.Х. Муаллими соний. Тошкент: Гафур Гулом номидаги нашриёт-матбаа ижодий уйи, 2018.

Мамытов С.А. Татарско-кыргызские литературные связи второй половины XIX – начала XX вв.: Автореф. дис. ... к. филол. н. Казань: 1992.

Насретдинова Д.М. Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги). Тарих ф. дис. автореф. Тошкент, 2011.

Расулов А.Н. История взаимоотношений народов Туркестана, Поволжья и Приуралья (1917–1924): автореф. дис. … докт. ист. наук. Ташкент, 2005.
Турсунова М. Мадрасалар таълими тариҳидан лавхалар. Тошкент, 2017.

**Автор турында белешмә:** Мортазина Ләлә Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗәни исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); lyalyamur@mail.ru

*Редакциягә керде 23.01.2020* *Басылуга кабул ителде 27.10.2020*
*Онлайн басылды 27.11.2020*

# JADIDIST SCHOOLS IN TURKESTAN AND TATARS (BASED ON MATERIALS OF THE TATAR AND UZBEK PRESS OF EARLY 20TH CENTURY)

***L.R. Murtazina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

The article highlights contribution of Tatar teachers in organizing Jadidist schools and educating children of the local peoples in Turkestan. Opinions of scientists of the early twentieth century, the Soviet period, and also modern researchers on this problem are presented. Based on the materials from newspapers and magazines of the early 20th century in the Tatar and Uzbek languages, the article highlights the history of the opening of certain schools and their activities. The issues of the the local population representatives' attitide to the work of Tatar teachers are revealed. In addition, the role and influence of Tatar teachers and their textbooks on publishing educational literature written in the Turkestan peoples' languages is also emphasized.

**Keywords:** Jadidism, Central Asia, Turkestan, Tatar teachers (mugallim), sound method ("yusuli sautiya"), Jadid schools, madrassas, related peoples, education

**For citation:** Murtazina L.R. Törkestanda jädit mäktäpläre häm tatarlar (XX gasyr bashy tatar häm üzbäk vakytly matbugaty materiallary buencha) [Jadidist schools in Turkestan and Tatars (based on materials of the Tatar and Uzbek press of early 20th century)]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 3, pp. 466–480. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-3.466-480

REFERENCES

Bartold V.V. *Istoriya kul'turnoy zhizni Turkestana* [The History of the Cultural Life of Turkestan]. Leningrad, USSR Academy of Sciences Publ., 1927. (In Russian)
Dobromyslov A.I. *Tashkent v proshlom i nastoyashchem* [Tashkent in the past and the present]. Tashkent: O.A. Portsev Elektric Steam Typolithogr., 1912. (in Russian)

Galimova A.R. *Literaturnyye svyazi kirgizskoy i tatarskoy poezii kontsa XIX – pervoy poloviny XX v.* [Literary Relations of the Kirghiz and Tatar poetry of the Late 19th – the First Half of the 20th Century]. Bishkek, Kirghiz-Russian Slavic University Publ., 2015. (In Russian)

Imankulov M.K. Razvitiye sistemy obrazovaniya v nachale XX veka [The Development of the Education System in the Early 20th Century]. *Izvestiya Kyrgyzskoy akademii obrazovaniya*, 2016, no. 1 (37), pp. 42–46. (In Russian)

Karlybayev M.A. “Tatarskiye” knigi v mektebakh Karakalpakii v nachale 20 veka [The "Tatar" Books in Schools of Karakalpakstan in the Early 20th Century]. *Tyurkoyazychnaya kniga: naslediye vekov*. Kazan, Institute of Language, Literature and History Publ., 2012, pp. 112–114. (In Russian)

Kubatova A.E. *Kyrgyzstandany zhadidchilik kyjmyly (1900–1916)* [Jadid Movement in Kirghizstan (1900–1916)]. Bishkek, 2012. (In Kyrgyz)

Maksudi H.A. *Muallimi soniy* [The Second Teacher]. Tashkent, Gafur Gulum Publ. House, 2018. (In Uzbek)

Mamytov S.A. *Tatarsko-kirghizskiye literaturnyye svyazi vtoroy poloviny XIX – nachala XX vekov. Avtoref. Diss. Cand. filol. nauk* [Tatar-Kirghiz Literary Relations of the Second Half of the 19th – early 20th centuries. Abstract of Cand. Sc. Philology Diss.]. Kazan, 1992. (in Russian)

Nasretdinova D.M. *Turkistonning madaniy ҳaetida tatar-boshқird aellarining tutgan ўrni (XIX asr okhiri – XX asrning birinchi choragi). Tarikh f. Diss. Avtoref.* [The Role of Tatar-Bashkir Women in the Cultural Life of Turkistan (Late 19th – the First Quarter of the 20th Centuries). Abstract of Cand. Sc. History Diss.]. Tashkent, 2011. (In Uzbek)

Rasulov A.N. *Istoriya vzaimootnosheniy narodov Turkestana, Povolzh'ya i Priural'ya (1917–1924). Avtoref. Diss. Doct. ist. nauk* [The History of Relations between the Peoples of Turkestan, the Volga Region, and the Ural Provinces (1917–1924). Abstract of Doctor Sc. History Diss.]. Tashkent, 2005. (In Russian)

Tursunova M. *Madrasalar ta"limi tarihidan lavhalar* [Stories on the History of Madrasahs]. Tashkent, 2017. (In Uzbek)

Zuluev B.B. Literatura dzhadidistov i aktivnost' vypusknikov v obshchestvennoj zhizni [Jadidist Literature and Graduate Activity in Public Life]. *Mezhdunarodnyy zhurnal eksperimental'nogo obrazovaniya*, 2018, no. 6, pp. 5–10. (In Russian) Available at: http://expeducation.ru/ru/article/view?id=11812

**About the author:** Lyalya R. Murtazina is Cand. Sc. (Pedagogy), Leading Research Fellow at the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru

*Received January 23, 2020 Accepted for publication October 27, 2020*
*Published November 27, 2020*

# ДЖАДИДИСТСКИЕ ШКОЛЫ В ТУРКЕСТАНЕ И ТАТАРЫ (НА ОСНОВЕ МАТЕРИАЛОВ ТАТАРСКОЙ И УЗБЕКСКОЙ ПРЕССЫ НАЧАЛА XX ВЕКА)

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье освещается деятельность татарских мугаллимов в организации джадидистских школ и обучении татар и детей местных народов в Туркестане. Приводятся точки зрения на эту проблему ученых начала XX в., советского периода и современных исследователей. На основе материалов периодической печати на татарском и узбекском языках начала XX в. освещается история открытия и деятельности отдельных школ. Раскрываются некоторые вопросы отношения представителей местного населения на деятельность татарских учителей, подчеркивается роль и влияние татарских педагогов и их учебников на создание учебной литературы на языках народов Туркестана.

**Ключевые слова:** джадидизм, Средняя Азия, Туркестан, татарские учителя (мугаллимы), звуковой метод (*ысулы саутия*), джадидские школы, медресе, родственные народы, просвещение

**Для цитирования:** Муртазина Л.Р. Төркестанда җәдит мәктәпләре һәм татарлар (XX гасыр башы татар һәм үзбәк вакытлы матбугаты материаллары буенча) // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 3. С. 466–480. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-3.466-480

**Сведения об авторе:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник Центра истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

*Поступила 23.01.2020* *Принята к публикации 27.10.2020*
*Опубликована 27.11.2020*